РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» 07 2019 г. №474

“Гражданнарны социаль найм һәм
башка дәүләт торак программалары
буенча исәпкә куйганда, һәм торак белән
тәэмин иткәндә, торак мәйданы нормалары турында”

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясын гамәлгә ашыру һәм гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2006 елның 13июлендәге “Гражданнарны социаль найм һәм башка дәүләт торак программалары буенча исәпкә куйганда, һәм торак белән тәэмин иткәндә, торак мәйданы нормалары турында”гы 119 санлы карарын һәм 2009 елның 19 августындагы "Башкарма комитетның 2006 елның 13 июлендәге 119 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында “ 110 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Гражданнарны торакка мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, (аннан чыгып аларның торак мәйданы белән тәэмин ителеше билгеләнә), торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасын гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмдә билгеләргә.

3. Социаль найм шартнамәсе һәм дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв. м. күләмендә торак урыны мәйданы нормасын билгеләргә, ләкин ялгыз яшәүче граждан өчен торакның гомуми мәйданы 42 кв.метрдан артмаска һәм ике кешедән торган гаилә өчен торакның гомуми мәйданы 50 кв. метрдан артмаска тиеш.

4. Карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче С. П. Самонина

Н.А. Абильтарова

2-76-81